Зур Сәрдек авыл җирлеге Советы
Кукмара муниципаль районы
Татарстан Республикасы

# КАРАРЫ

09 июнь 2021 ел №14

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль
районы Зур Сәрдек авыл җирлегенең Җирдән файдалану
һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 20 пункты, Зур Сәрдек авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы «Зур Сәрдек авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» Зур Сәрдек авыл җирлеге Советының 2014 елның 30 гыйнварындагы 3 номерлы карары (2016 елның 16 декабренда 36 номерлы, 2018 елның 21 июнендәге 15 номерлы, 2019 елның 20 февралендәге 3 номерлы, 2019 елның 29 августындагы 13 номерлы Зур Сәрдек авыл җирлеге Советы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы «Зур Сәрдек авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең «Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә», 18.1 статьясын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә.

«18. 1. Җир кишәрлекләренең иң чик күләмнәре:

«Шәхси торак төзелеше», «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» рөхсәт ителгән файдалану рәвешендәге җир кишәрлекләренең минималь күләме – 1 000 кв.м.

«Шәхси торак төзелеше» рөхсәт ителгән файдалану рәвешендәге җир кишәрлегенең максималь күләме – 2500 кв.м, «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» – 5000 кв.м.»

2. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлегеннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 9 июнендәге 8 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Зур Сәрдек Авыл Җирлеге Башлыгы Ф.М.Фаттахов